| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 31.03.2022 | с. Большие Полянки | № 24 |

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында» 2013 елның 25 апрелендәге 100 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2022 елның 15 февралендәге гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен (тәкъдимнәрен) исәпкә алып,

**Зур Полянка авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 апрелендәге 100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында: Зур Полянка авылының үзәк өлешендә, Бутлеров урамында, Ж1 территориаль зонаның (шәхси торак төзелеше зонасы) бер өлешен ОД1 территориаль зонасына (күп функцияле иҗтимагый-эшлекле зона) алмаштырырга. Үзгәртелгән территориаль зонаның гомуми мәйданы 0,16 га тәшкил итә. Әлеге территориаль зонаны үз эченә алган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:05:030101:780; 16:05:030101:782. Әлеге территориаль зонаның урнашу урынының кадастр кварталы: 16:05:030101; Красный Баран авылының үзәк өлешендә, Үзәк урамы, 58а з/у, 58б з/у, Ж1 территориаль зонасының бер өлеше (шәхси торак төзелеше зонасы) ОД1 территориаль зонасына (күп функцияле иҗтимагый-эшлекле зона) алмаштырырга. Үзгәртелгән территориаль зонаның гомуми мәйданы 0,115 га тәшкил итә. Әлеге территориаль зонаны үз эченә алган

җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:05:030201:752; 16:05:030201:753. Әлеге территориаль зонаның урнашу урынының кадастр кварталы: 16:05:030201 (Кушымта).

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зур Полянка авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы** **М.Р. Афанасьева**

Зур Полянка авыл җирлеге
Советының 2022 елның 31
мартындагы 24 номерлы
карарына кушымта




Зур Полянка авыл җирлегенең шәһәр төзелеше зоналашуы картасының фрагменты, Зур Полянка авылы (хәзерге хәле)




Зур Полянка авыл җирлегенең шәһәр төзелеше зоналашуы картасының фрагменты, Зур Полянка авылы (кертелә торган үзгәрешләр)




Зур Полянка авыл җирлегенең шәһәр төзелеше зоналашуы картасының фрагменты, Красный Баран авылы (хәзерге хәле)




Зур Полянка авыл җирлегенең шәһәр төзелеше зоналашуы картасының фрагменты, Красный Баран авылы (кертелә торган үзгәрешләр)